

**Июнь килде: "Июнь! Июнь!"**
**Бакчада кошлар сайрый**
**Тузганакка өрсәң әгәр -**
**Бер бөртеге дә калмый**

## Июнь – ел фасылының иң-иң назлысы

Июнь аенда үлән арасында чикерткә тавышы хәтта төннәрен дә тынмый. Кигәвен һәм чебен-черки турында сөйлисе дә түгел. Июньдә төннәр кыскара. Аның каравы, көннәрнең озынлыгы үзенең югары ноктасына житешә. Елның шушы фасылында тырышлык салып калганда, көзге муллык тәэмин ителде дип фаразларга мөмкин.

## Сынамышлар

Июньдә яңгыр еш төшсә, гөмбә күп булыр.
Өчесендә булса төшлектә жил — сабан ашлыгына килә ел.
Сигезендә яшенләсә яшен, жыя алмассың печәнең яшел.
Егерме жидесендә яңгырлы — жиде атна яңгырлы.
Иртә белән чык күп төшсә, бик эссе булыр.



## Табышмак әйтәм, җавабын тап!

Сыр-сыр сыры бар,
Алты төрле нуры бар,
Жиде кат күккә юлы бар.
(Салават күпере)

## Әйтенү “Чикерткә”

Әйт әле, чикерткә,
Сине нәрсә сикертә?
Сайрый белми сайрыйсың
Бертуктамый кич – иртә.
Бер сикердең – котылдың,
Ике сикердең – котылдың,
Өченчесендә – тотылдың!
Һап!

